КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1031

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 23 июль, 589 нчы карары белән расланган 2024 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» субсидияләр рәвешендә грантларын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем

бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» субсидияләр рәвешендә грантларын бирү турында» 2024 ел, 23 июль, 589 нчы карары белән расланган 2024 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә һәм «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм» субсидияләр рәвешендә грантларын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Грант федераль проект кысаларында Татарстан Республикасында алдынгы югары белем бирү мәгариф оешмалары базасында алдынгы инженерлык мәктәпләренең югары технологияле компанияләре белән партнерлыкта төзелгән, инженерлык әзерлегенең яңа төрен булдыру, Россия Федерациясе технологик үсешенең өстенлекле өлкәләрендә алга киткән эшләнмәләрне һәм тикшеренүләрне гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасының яңа икътисад тармакларын формалаштыру һәм үстерү өчен фәнни-технологик нигез булдыру, иң яхшы магистр программалары буенча талантлы студентлар өчен практикалар һәм стажировкалар (шул исәптән остазлар белән эшләү форматында) узу, алдынгы инженерлык мәктәпләренең, шулай ук инженерлык юнәлешендәге белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирү мәгариф оешмаларының профессор-мөгалимнәр составына һәм идарә итүче командаларына квалификация күтәрү һәм (яисә) яңадан һөнәри әзерләү (шул исәптән югары технологияле компанияләр базасында стажировка үтү рәвешендә) өчен шартлар тәэмин итүгә юнәлдерелгән үсеш программаларына ярдәм күрсәтү максатларында бирелә.»;

16 пунктның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. 2024 елда грант бирү нәтиҗәсе – югары белем бирү мәгариф оешмалары тарафыннан федераль проект кысаларында алдынгы инженерлык мәктәпләренең югары технологияле компанияләре белән партнерлыкта төзелгән, инженерлык ягыннан әзерлекне, Россия Федерациясе технологик үсешенең өстенлекле өлкәләрендә алга киткән эшләнмәләрне һәм тикшеренүләрне үстерүгә юнәлдерелгән кимендә бер программа гамәлгә ашырылу.»;

20 пунктта:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацта «беренче һәм икенче абзацларында» сүзләрен «беренче

абзацында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 23 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин